СОВЕТ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

06.05.2025 г. Заинск № 397

**Зәй муниципаль районы Советының 2019 елның 20 маендагы 397 номерлы «Муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәт өчен түләүне оештыру турындагы Нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы Советының «Муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәт өчен түләүне оештыру турында Нигезләмә хакында» 2019 елның 20 маендагы 397 номерлы карары белән расланган Муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре булган үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәт өчен түләүне оештыру турындагы нигезләмәгә (Зәй муниципаль районы Советының 27.08.2020 ел № 554, 18.11.2022 ел № 246, 13.06.2024 ел № 335, 09.12.2024 ел № 364 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Вазыйфаи окладлар түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сумнар |
|---|---|
| Баш хисапчы | 34 600 |
| Бүлек башлыгы | 30 500 |
| Алып баручы бухгалтер | 27 800 |
| Әйдәп баручы икътисадчы | 27 800 |
| Әйдәп баручы белгеч | 27 800 |
| Бухгалтер | 26 400 |
| Икътисадчы | 26 400 |
| Белгеч | 26 400 |

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш. ».

2. Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» на (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Билгеләргә:

әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә;

әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары П. С. Уразайкинга йөкләргә.

**Совет рәисе** **Р.Г. Кәримов**